Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә капиталь һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2006 елның 28 сентябрендәге 397 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә капиталь һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү Тәртибенең 2 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1.10 пунктта** «яисә индивидуаль торак төзелеше объектын урнаштыру урынын билгеләп, җир кишәрлеген планлаштыру оешмасы схемасының бер нөсхәсе» сүзләрен төшереп калдырырга;

**2.4 пунктының** икенче абзацында «гараж төзү» сүзләрен «гараж төзү, реконструкцияләү» сүзләренә алмаштырырга, «бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлегендә» сүзләрен «торак йортның, бакча йортының, хуҗалык корылмаларының төзелеш, реконструкцияләү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы Д.А. Сатдинов